**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУРКАЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422730, Высокогорский район РТ,
п. ж/д. разъезда Куркачи,
ул. Гагарина, 7

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОРКАЧЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422730, ТР Биектау районы,
Коркачык тимер юл разъезды поселогы,
Гагарин ур., 7

Тел./факс: +7(84365) 71-2-15, e-mail: Kurk.Vsg@tatar.ru

---

**КАРАР** | **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

от 20.04.2015 | № 5

**Гражданнарга хәбәр итү һәм илтеп бирү турында, хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле кешеләр Коркачык авыл җирлегендә 2015 елның апрель – июль айларында.**

«Оборона турында» 31.05.1996 елдагы 61-ФЗ номерлы, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 28.03.1998 елдагы 53-ФЗ номерлы федераль законнар, «Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә чакыру турында нигезләмәне раслау хакында» 11.11.2006 елдагы 663 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары нигезендә, чакырылышны вакытында һәм сыйфатлы башкару максатларында Коркачык авыл җирлеге гражданнарының хәрби хезмәткә 2015 елның апрель – июлендә запастагы һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле 18 яшьтән 27 яшькә кадәр»,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Хәрби хезмәткә чакырылуга бәйле чаралар үткәрү өчен хәрби хезмәткә чакырылучыларны хәбәр итүне оештыру.
2. Хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарның үз вакытында оештырылган килүен тәэмин итәргә.
3. Участок уполномоченные Д. и. Сәлаховка Биектау районының хәрби комиссариат бүлегенә чакырылудан качып йөрүче егетләрнең килүен тәэмин итүдә ярдәм күрсәтергә киңәш итәм.
4. Хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затларның барлык милек рәвешләрендәге предприятие һәм оешма җитәкчеләренә армиягә чакыру компаниясе уздыру чорында торак пунктлардан читкә чыгу белән бәйле эштән һәм хезмәт бурычларын үтәүдән азат итилергә тиеш.
5. Әлеге карарны Коркачык авыл җирлегенең мәгълүмат стендында һәм Биектау муниципаль районының интернет челтәре сайтында урнаштырырга.
6. Әлеге карар аны имзалаган көннән үз көченә керә һәм Коркачык авыл җирлегенең мәгълүмат стендында һәм Биектау муниципаль районының интернет челтәрендә рәсми рәвештә игълан итилергә тиеш.
7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет секретаре Р. Р. Хәкимовага йөкләргә.

Коркачык авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе К.Ф. Хайбуллина